**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТУРАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

КАРАР

№ 17 13.12.2019 елдан

Турай авыл җирлеге территориясендә
халык тарафыннан
пиротехник эшләнмәләрне куллану урыннарын
билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Янгынга каршы режим турында» 25.04.2012 ел, № 390 карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «пиротехник эшләнмәләрне таратканда һәм кулланганда янгын куркынычсызлыгы таләпләрен раслау турында» 2009 ел, 22 декабрь, 1052 нче карары белән һәм Яңа ел бәйрәмнәре чорында бәхетсезлек очракларын булдырмау максатларында

КАРАР ИТӘМ:

1. Алар белән эш итү махсус белемнәр һәм күнекмәләр таләп ителмәгән I - III класслардагы көнкүреш билгеләнешендәге пиротехник эшләнмәләрдән (ГОСТ Р 51270-99) файдалану урыннарын билгеләргә:

– Тураево авылы – Овражная урамындагы 39 нчы йорт артындагы буш урында;
– Тат.Ахтиялы авылы – Ключевая урамындагы 47 нче йорт артындагы мәйданчыкта.

2. пиротехника әйберләрен куллану урыннарын янгын сүндерү өчен кирәкле күләмдә беренчел чаралар һәм мәгълүмат стендлары белән җиһазландырырга:
- Авыл җирлеге башлыгының пиротехника әйберләрен эшләтеп җибәрү өчен мәйданчыклар урнаштыру урынын раслау турындагы карары;
- пиротехник эшләнмәләр кулланганда куркынычсызлык чаралары буенча белешмәләр.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Турай авыл җирлеге Башлыгы А.М.Рахимова